ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫЋ ДЂЊЛЂТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Краснаяур. 15/9, Казан шђџђре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 184

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«09» декабря 2014 г.

**2013 елның 31 октябрендәге “Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъвалык итүче граждданнар тарафыннан керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында”гы 149 номерлы боерыкка үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге “Керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә рәвешен раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 460 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге “Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъвалык итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы”ПУ-702 номерлы Указы нигезендә **б о е р ы к б и р ә м**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең (алга таба – ТР ДТИ) 2013 елның 31 октябрендәге 149 номерлы Боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъвалык итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 һәм 4 пунктларда “расланган белешмәләр рәвеше буенча” сүзләрен “Россия Федерациясе Президенты раслаган белешмә рәвеше буенча” сүзләре белән алмаштырырга;

8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданлык хезмәткәре җентекләнгән белешмәләрне әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән вакыт узганнан соң бер ай дәвамында тапшырырга мөмкин. Дәүләт хезмәтенә билгеләнә торган граждан җентекләнгән белешмәләрне Нигезләмәнең 3 пункты нигезендә белешмәләр тапшырылган көннән соң бер ай дәвамында тапшырырга мөмкин»;

Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъвалык итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә карата кушымтаны кушымта булып килүче яңа редакциясендә бәян итәргә.

2. Кадрлар бүлеге башлыгына (И.Н. Никитина) әлеге боерык белән Инспекциядәге барлык дәүләт хезмәткәрләрен таныштырырга.

3. Хокукый идарәнең юридик бүлек башлыгына (А.Н. Гафиятуллин) әлеге боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлеге башлыгына (И.С. Начвин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында теркәгәннән соң Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык С.А. Крайнов